КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 28 июль г.Казань № 611

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчерү һәм саклау хезмәтләре күрсәтүчене сайлап алу буенча сатулар оештыру һәм үткәрү, тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга тарифларны билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексының 27.13 статьясы, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга тарифларны исәпләп чыгару һәм түләү вакытларын билгеләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 ел, 15 август, 1145/16 нчы боерыгы, «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» 2012 ел, 17 май, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчерү һәм саклау хезмәтләре күрсәтүчене сайлап алу буенча сатулар оештыру һәм үткәрү, тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга тарифларны билгеләү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 28 июль, 611 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын
күчерү һәм саклау хезмәтләре күрсәтүчене сайлап алу буенча сатулар
оештыру һәм үткәрү, тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә
һәм саклауга тарифларны билгеләү
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчерү һәм саклау хезмәтләре күрсәтүчене сайлап алу буенча сатулар оештыру һәм үткәрү кагыйдәләрен билгели. Сатулар нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга тарифлар (алга таба – тарифлар) билгеләнә.

2. Сатулар бәяне киметүгә аукцион рәвешендә (алга таба – аукцион) үткәрелә.

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнгән тарифларның база дәрәҗәсе аукционның башлангыч максималь бәясе булып тора.

Әгәр дә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре буенча тарифларны дифференциацияләү турында карар кабул ителсә, аукцион хезмәтләр күрсәтүчене сайлап алу буенча тиешле муниципаль берәмлекләрдә үткәрелә, башка очракларда, аукцион хезмәтләр күрсәтүчене сайлап алу буенча Татарстан Республикасының барлык территориясендә үткәрелә.

3. Аукционны оештыруга һәм үткәрүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы (алга таба – оештыручы) булып Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тора.

4. Аукцион үткәрү турындагы белдерү (алга таба – белдерү) оештыручы тарафыннан булдырыла һәм оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында аукционда катнашуга гаризалар бирү вакыты тәмамланганга кадәр кимендә 15 календарь көн кала бастырып чыгарыла.

Белдерүдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

аукционның тарифларның база дәрәҗәсенә тигез булган башлангыч бәясе;

оештыручының исеме, адресы, телефон номерлары;

аукционда катнашуга гаризалар кабул итүнең һәм кабул итеп бетерүнең датасы, урыны һәм вакыты;

аукционда катнашуга гаризаларны карап тикшерү вакыты;

аукционны үткәрә башлау вакытын һәм аукционга йомгаклар ясау вакытын күрсәтеп, аукцион үткәрү датасы һәм урыны;

бәя кимү дәрәҗәсе (адымы) (алга таба – «аукцион адымы»).

5. Аукционның предметы түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчерү бәясен түләү өчен тариф билгеләү;

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын саклау бәясен түләү өчен тарифлар билгеләү.

6. Аукцион үткәрү өчен аукцион комиссиясе (алга таба – комиссия) төзелә.

Комиссия ведомствоара булып тора һәм Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары һәм федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары хезмәткәрләреннән (килешү буенча) төзелә.

Комиссия әгъзаларының саны кимендә биш кеше булырга тиеш. Оештыручы белдерүне бастырганга кадәр комиссия составы буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертә.

Комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Комиссия утырышы, анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы булып санала.

7. Аукционда Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән, аукцион предметы (предметлары) нигезендә тоткарланган транспорт чараларын күчерү һәм (яки) саклау буенча хезмәтләр күрсәтүче яки хезмәтләр күрсәтүгә нияте булган, аукционда катнашуга гариза биргән (алга таба – гариза бирүче) һәм оештыручы тарафыннан аукционда катнашуга кертелгән (алга таба – аукционда катнашучы) теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр катнаша ала.

8. Гариза бирүче түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

бетерү яки бүлеп бирелү яки бүленү рәвешендә үзгәртеп оештыру процессында булмаса;

гариза бирүченең эшчәнлеге Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы белән билгеләнгән тәртиптә туктатылмаса;

гариза бирүчегә карата банкротлык турында эш кузгатылмаса, арбитраж судның юридик затны яки индивидуаль эшмәкәрне акча түләүгә сәләтсез (банкрот) дип тану турында һәм конкурс җитештерүен ачу турында карары булмаса;

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчерү һәм саклау өчен файдаланырга күздә тотыла торган мөлкәткә арест салынмаса;

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган машина кую урыннарына күчерү максатларында файдалану өчен билгеләнгән махсус транспорт чараларына (автоэвакуаторларга) һәм Татарстан Республикасындагы тоткарланган транспорт чараларын саклау өчен махсус машина кую урыннарын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә, машина кую урыннарына, күпдәрәҗәле (күпкатлы) паркингларга законлы нигездә ия булса.

9. Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган машина кую урыннарына күчерү максатларында файдалану өчен билгеләнгән махсуслаштырылган транспорт чаралары (автоэвакуаторлар) түбәндәге техник таләпләргә туры килергә тиеш:

автоэвакуатор платформасына транспорт чараларын төяү һәм аннан төшерү өчен билгеләнгән җиһазлар белән җиһазландырылган кран-манипулятор җайланмасы булу;

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, шул исәптән торак пунктларның урам-юл челтәре буенча автоэвакуаторның хәрәкәт итү мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, тоткарланган һәм автоэвакуатор платформасына төялгән транспорт чарасы булган автоэвакуаторның конструктив максималь биеклеге 3 900 мм артмаска тиеш;

йөк күтәрүчәнлеге – кимендә 3 500 кг;

ГЛОНАСС спутник навигациясе аппаратурасы белән тәэмин ителү.

Транспорт чараларын тоткарлау турындагы карарларны үтәү мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, гариза бирүче мондый карар кабул ителгән вакыттан бер сәгать эчендә тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган машина кую урынында саклый башлаганга кадәр кимендә тугыз махсуслаштырылган транспорт чарасын (автоэвакуаторны) бер үк вакытта эксплуатацияләргә тиеш.

10. Татарстан Республикасындагы тоткарланган транспорт чараларын саклау өчен махсуслаштырылган урыннарны булдыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре, машина кую урыннары, күпдәрәҗәле (күпкатлы) паркинглар (алга таба – махсуслаштырылган машина кую урыннары) түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

каты катлам (асфальт-бетон, бетон һ.б.ш.) белән яки ташлар (чуерташ, вак таш һ.б.ш.) белән түшәлгән булу;

территориядә кимендә 40 транспорт чарасын саклауны тәэмин итәргә тиеш;

махсуслаштырылган машина кую урыны периметры буенча коймалар (металл, бетон һ.б.ш.) булу;

махсуслаштырылган машина кую урыны территориясенең ясалма яктырткычы булу;

тоткарланган транспорт чараларын төяү һәм төшерү максатларында, бу Тәртипнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән техник тасвирнамәләр белән махсус транспорт чараларын (автоэвакуаторларны) махсуслаштырылган машина кую урыны территориясендә эксплуатацияләү мөмкинлеген тәэмин итү.

Тоткарланган транспорт чараларын саклауны тәэмин итү максатларында, гариза бирүченең Татарстан Республикасы буенча кимендә 25 махсуслаштырылган машина кую урыны булырга тиеш.

11. Гариза бирүчегә оештыручы тарафыннан түбәндәге очракларда аукционда катнашырга рөхсәт ителми:

бу Тәртипнең 8 – 10 нчы пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән;

аукционда катнашуга гариза бу Тәртипнең 13 – 15 нче пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән;

дөрес булмаган мәгълүматны үз эченә алган документлар тапшырган;

белдерүдә күрсәтелгән гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән һәм (яки) вакыттан соң аукционда катнашуга гариза тапшырган.

12. Бу Тәртипнең 11 нче пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, башка нигезләр буенча аукционда катнашудан баш тарту рөхсәт ителми.

13. Гариза бирүче яки аукционда катнашучы тарафыннан бу Тәртипнең 15 нче пункты нигезендә тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмау факты ачыкланган очракта, оештыручы мондый гариза бирүчене яки аукционда катнашучыны аукционның теләсә кайсы үткәрү этабында аукционнан чыгарырга тиеш.

14. Аукционда катнашырга рөхсәт бирү бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча тапшырылган гариза һәм бу Тәртипнең 15 нче пунктында каралган һәм аңа теркәлгән мәгълүматлар һәм документлар нигезендә гамәлгә ашырыла. Тапшырылган документларның һәм мәгълүматларның дөреслеге өчен гариза бирүче җавап бирә.

15. Аукционда катнашуга гаризада түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

тулы һәм кыскартылган исеме, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны, телефон номеры, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры – юридик затлар өчен;

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шәхесне раслый торган документ мәгълүматлары, яшәү урыны турында мәгълүматлар, телефон номеры, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры, Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль шәхси исәпнең иминият номеры – индивидуаль эшмәкәрләр өчен.

Аукционда катнашуга гаризага түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

аукционда катнашучының гамәлгә кую документлары күчермәләре (юридик затлар өчен);

Татарстан Республикасындагы тоткарланган транспорт чараларын саклау өчен махсуслаштырылган урыннарны ясау өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә, машина кую урыннарына, күпдәрәҗәле (күпкатлы) паркингларга милек хокукын (башка әйбер хокукын) раслый торган документлар күчермәләре;

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган машина кую урыннарына күчерү максатларында файдалану өчен билгеләнгән махсус транспорт чараларына (автоэвакуаторларга) милек хокукын (башка әйбер хокукын) раслый торган документлар (шул исәптән теркәү документлары) күчермәләре;

махсуслаштырылган транспорт чараларының (автоэвакуаторларның) бу Тәртипнең 9 нчы пунктында каралган таләпләргә туры килүен раслый торган документлар күчермәләре;

махсуслаштырылган машина кую урыннарының бу Тәртипнең 10 нчы пунктында каралган таләпләргә туры килүен раслый торган документлар, фотоматериаллар күчермәләре;

затның гариза бирүче исеменнән гамәлләр башкаруга вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр дә ул гариза бирүче вәкиле тарафыннан тапшырылса).

16. Аукционда катнашуга гариза һәм аңа теркәлә торган документлар тегелгән, номерланган, гариза бирүче яки гариза бирүченең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган яки гариза бирүче мөһере белән беркетелгән (булган очракта) документларның бердәм пакеты итеп булдырылырга тиеш.

17. Аукцион үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән вакытта кергән аукционда катнашуга гариза кергән көндә оештыручы тарафыннан теркәлә.

Аукционда катнашу өчен белдерүдә күрсәтелгән мондый гаризаларны кабул итү тәмамланган көннән һәм (яки) вакыттан соң кергән гариза карап тикшерелми

һәм оештыручы тарафыннан гариза бирүчегә гариза кергән көннән соң килүче бер эш көне эчендә кире кайтарыла.

18. Аукционда катнашуга гариза тапшырган гариза бирүче мондый гаризаларны бирү вакыты тәмамланганга кадәр аны теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы.

19. Оештыручы аукционда катнашуга гаризаларның бу Тәртипнең 14 – 16 нчы пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә. Аукционда катнашуга гаризаларны карап тикшерү вакыты аларны бирү вакыты тәмамланган көннән соң 10 календарь көннән дә артмаска тиеш.

20. Аукционда катнашуга гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча оештыручы гариза бирүчегә аукционда катнашырга рөхсәт бирү һәм аны аукционда катнашучы дип тану турында яки гариза бирүчегә аукционда катнашырга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гариза бирүчеләргә, гаризаларны карап тикшерү вакыты тәмамланган көннән соң килүче ике эш көненнән дә соңга калмыйча, кабул ителгән карарлар турында хәбәрнамә җибәрә.

Әлеге карар, гаризаларны карап тикшерү вакыты тәмамланган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, аукционда катнашуга гаризаларны карап тикшерү беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

21. Аукционда катнашуга гаризаларны карап тикшерү беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

гариза бирүчеләрне күрсәтеп, аукционда катнашу өчен теркәлгән гаризалар турында мәгълүматлар;

аукционда катнашуга гаризалар бирү датасы һәм вакыты;

кире алынган аукционда катнашуга гаризалар турында мәгълүмат;

аукционда катнашучылар дип танылган гариза бирүчеләрнең исемнәре;

аукционда катнашучылар дип танудан баш тарылган гариза бирүчеләрнең исемнәре (мондый баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп).

Аукционда катнашуга гаризаларны карап тикшерү беркетмәсе, аңа кул куелган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, оештыручы тарафыннан аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

22. Аукцион анда катнашуга гаризаларны карап тикшерү вакыты тәмамлангач өч эш көненнән соң үткәрелә. Аукционда катнашучылар дип танылган гариза бирүчеләр аукционда катнаша ала.

23. Аукцион белдерүдә күрсәтелгән «аукцион адымы»на бәяне киметү юлы белән үткәрелә.

24. Аукцион түбәндәге тәртиптә үткәрелә:

а) оештыручы аукцион үткәрүне башлап җибәрү алдыннан аукционда катнашуга кертелгән һәм аукционга килгән, номерланган карточкалар (алга таба – карточкалар) бирелгән аукционда катнашучыларны (аларның вәкилләрен) билгели;

б) аукцион комиссия рәисенең аукционны үткәрә башлау, аукционның предметы, аның бәясе, «аукцион адымы» турындагы белдерү белән башлана, аннан соң комиссия рәисе аукционда катнашучыларга түбәндәге предметлар буенча үз тәкъдимнәрен белдерергә тәкъдим итә:

тоткарланган транспорт чараларын күчерүнең «аукцион адымы»на киметелгән

бәясен түләү өчен тариф билгеләү;

тоткарланган транспорт чараларын саклауның «аукцион адымы»на киметелгән бәясен түләү өчен тарифлар билгеләү;

в) аукционда катнашучы, комиссия рәисе тарафыннан аукционның «аукцион адымы»на киметелгән предметы (предметлары) буенча тәкъдим игълан ителгәннән соң, әгәр дә ул предмет (предметлар) буенча игълан ителгән тәкъдим белән килешсә, карточкасын күтәрә. «Аукцион адымы»на киметелгән предмет (предметлар) буенча тәкъдимнәр игълан ителгәннән соң карточка күтәргән катнашучыларның берсе тарафыннан ризалык белдерелгән дип санала;

г) әгәр дә комиссия рәисе тарафыннан «аукцион адымы»на киметелгән предмет (предметлар) буенча чираттагы тәкъдим өч тапкыр игълан ителгәннән соң аукционда катнашучының берсе дә карточкасын күтәрмәсә, аукцион тәмамланган дип санала. Бу очракта комиссия рәисе предмет (предметлар) буенча ясалган соңгы тәкъдимне һәм соңгы тәкъдим ясаган катнашучыны (хезмәтләр күрсәтүчене) игълан итә.

25. Тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга минималь тарифлар игълан иткән катнашучы хезмәт күрсәтүче булып танала.

26. Аукционга йомгаклар аукцион үткәрелгән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча ясала һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәдә аукцион предметлары нигезендә тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм (яки) саклауга минималь тарифлар тәкъдим иткән катнашучы турындагы мәгълүматлар чагылдырыла. Аукцион үткәрү беркетмәсе беркетмәгә кул куелган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча оештыручының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

27. Аукцион түбәндәге очракларда үткәрелмәгән дип санала:

аукционда катнашуга гаризалар булмаганда;

аукционда катнашырга рөхсәт ителгән гариза бирүчеләр булмаганда;

комиссия рәисе тарафыннан «аукцион адымы»на киметелгән аукцион предметлары буенча игълан ителгән тәкъдимнәр буенча аукционда катнашучылардан тәкъдимнәр булмаганда.

Предмет (предметлар) буенча аукционда катнашуга гариза бер гариза бирүче тарафыннан бирелгәндә һәм комиссия тарафыннан мондый гариза бирүче бердәнбер катнашучы дип танылганда, аукцион үткәрелмәгән дип танала.

28. Әгәр аукцион үткәрелмәгән дип танылса, тарифлар билгеле бер база дәрәҗәләреннән югарырак булмаган күләмдә билгеләнә.

29. Тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга тарифларны билгеләү турындагы карар аукцион үткәрелгән көннән 10 эш көне эчендә аукцион үткәрү беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокук акты белән кабул ителә.

Татарстан Республикасында
тоткарланган транспорт чараларын
күчерү һәм саклау хезмәтләре
күрсәтүчене сайлап алу буенча
сатулар оештыру һәм үткәрү,
тоткарланган транспорт чараларын
күчерүгә һәм саклауга тарифларны
билгеләү тәртибенә
кушымта

Форма

Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын
күчерү һәм саклау хезмәтләре күрсәтүчене сайлап алу һәм
тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга
тарифларны билгеләү буенча сатуларда катнашуга
ГАРИЗА

Юридик затның исеме (индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (атасының исеме – булган очракта): ______________________________________
______________________________________________________________________

ОГРН/ИНН/КПП: ________________________________________________________

Юридик затны, индивидуаль эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турында документ: _________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Юридик затның адресы (индивидуаль эшмәкәрнең теркәлү адресы):
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Гариза бирүченең почта адресы: _________________________________________
______________________________________________________________________

Телефоны: __________________ Электрон почтасы: _________________________

Бу гаризада _____________________________________________________________
(гариза бирүченең исеме/фамилиясе, исеме, атасының исеме)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(аукцион предметы исеме)
предметы булып торган Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчерү һәм саклау хезмәтләре күрсәтүчене сайлап алу һәм тоткарланган транспорт чараларын күчерүгә һәм саклауга тарифларны билгеләү буенча сатуларда катнашырга теләген белдерә.

Кушымта: аукционда катнашу өчен бирелгән документлар реестры (битләрнең саны белән).

Гариза бирүче/гариза бирүченең вәкиле __________/_________________________/
(имза) (имза тулысынча)

Дата «___» ______________ 201__ ел М.У. (булган очракта)

_________________________________